**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет**

**Алькеевского сельского**

**поселения Азнакаевского**

**муниципального района**

**Пер.Советский,44а,423309**
**тел/факс (885592) 37-4-23**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль**
**районы Әлкәй авыл жирлеге**
**башкарма комитеты**

**Әлкәй авылы Совет тыкрыгы 44А**
**423309 тел/факс (885592) 37-4-23**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**03.07.2026 ел** **№8**

Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 21сентябрендәге 13 номерлы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге территориясендә хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә Координация советы турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге территориясендә хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә Координация советы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында «Федераль законның 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 25 маендагы 161-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 16 сентябрендәге 13 номерлы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге территориясендә хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә Координация советы турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге территориясендә хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә Координация советы турындагы Нигезләмәгә 2 пунктның 2.1 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле унҗиденче һәм унсигезенче абзацлар белән тулыландырып, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

“17) хәрби бурычны һәм хәрби хезмәтне үтәү;

18) тарихи дөреслекне яклауны тәэмин итү һәм Ватанны саклаганда халык батырлыгының әһәмиятен киметүгә юл куймау.».

2. Әлеге карарны түбәндәге веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo. tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм

"Интернет" мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча http://aznakayevo.tatar.ru. урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык А.Н.Арсланов